РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ
15 сентябрь 2023 ел.

КАРАР
№ 198

**Әтнә муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Әтнә муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

"Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 маендагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә район Советы карар чыгарды:

1. Әтнә муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәр, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Әтнә муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Әтнә район Советының 12.01.2015 ел, № 169 карары белән расланган Нигезләмәгә (20.02.2016 ел № 26, 20.05.2019 ел № 152, 22.05.2020 ел №207, 14.08.2023 ел № 190 редакцияләрендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

16 нчы пунктның икенче абзацын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итәргә:

"Муниципаль хезмәткәрләрнең үз чыгымнары турында мәгълүмат бирмәве, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, тулы булмаган мәгълүматны тәкъдим итү, яки үз чыгымнары турында дөрес булмаган мәгълүматны тәкъдим итү, яки хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүмат бирмәү, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, тулы булмаган мәгълүматны тәкъдим итү, яки, әгәр дә мондый мәгълүматны тәкъдим итү мәҗбүри булса, үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында ышанычсыз мәгълүмат бирү, аларны алмаштырыла торган вазифаларыннан азат итүгә, муниципаль хезмәттән билгеләнгән тәртиптә эштән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының (pravo.tatarstan.ru) рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әтнә муниципаль районы башлыгы-
район Советы Рәисе Г. Г. Хәкимов